ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**"Татарстан Республикасында дәүләти-хосусый партнерлык турында" Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2016 елның 21 апрелендә
кабул ителде

**1 статья**

"Татарстан Республикасында дәүләти-хосусый партнерлык турында" 2011 елның 1 августындагы 50-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2011, № 8 (I өлеш); 2012, № 3; 2014, № 6 (I өлеш), аны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәрешләр кертергә:

**"Татарстан Республикасында дәүләти-хосусый партнерлык турында**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗАКОНЫ

1 статья. **Әлеге Законның җайга салу предметы**

Әлеге Закон "Россия Федерациясендә дәүләти-хосусый партнерлык, муниципаль-хосусый партнерлык һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында" 2015 елның 13 июлендәге 224-ФЗ номерлы Федераль закон белән (алга таба – Федераль закон) Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте органнары компетенциясенә кертелгән мәсьәләләр буенча Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының дәүләти-хосусый партнерлык өлкәсендәге вәкаләтләрен билгели, шулай ук Татарстан Республикасының дәүләти-хосусый партнерлыкта катнашуының аерым мәсьәләләрен җайга сала.

2 статья. **Татарстан Республикасында дәүләти-хосусый партнерлык өлкәсендәге мөнәсәбәтләрне хокукый җайга салу**

1. Татарстан Республикасында дәүләти-хосусый партнерлык Россия Федерациясе Конституциясе, Татарстан Республикасы Конституциясе, Федераль

закон, Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актлары, әлеге Закон һәм Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары нигезендә гамәлгә ашырыла.

2. Әлеге Законда кулланылган төп төшенчәләр Федераль законда билгеләнгән мәгънәләрендә кулланыла.

3 статья. **Татарстан Республикасында дәүләти-хосусый партнерлыкның максатлары һәм принциплары**

1. Татарстан Республикасында дәүләти-хосусый партнерлыкның максатлары булып Татарстан Республикасы икътисадына хосусый инвестицияләр җәлеп итү, Татарстан Республикасының коммуналь, транспорт, социаль һәм башка инфраструктурасын үстерү өчен матди ресурсларны һәм финанс ресурсларын туплау, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары тарафыннан товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрнең һәркем файдалана алырлык булуын һәм аларның сыйфатын күтәрүне тәэмин итү тора.

2. Татарстан Республикасында дәүләти-хосусый партнерлык түбәндәге принципларга нигезләнә:

1) дәүләт серен һәм закон белән саклана торган башка серне тәшкил иткән белешмәләрдән тыш, дәүләти-хосусый партнерлык турындагы мәгълүматның ачыклыгы һәм һәркем файдалана алырлык булуы;

2) конкуренцияне тәэмин итү;

3) дискриминация булмау, дәүләти-хосусый партнерлык турында килешү төзегән якларның хокуклары бертигез булу һәм аларның закон каршында тигез хокуклы булуы;

4) дәүләти-хосусый партнерлык турында килешү төзегән якларның килешү йөкләмәләрен намуслы үтәве;

5) ихтимал булган куркынычларны һәм йөкләмәләрне дәүләти-хосусый партнерлык турында килешү төзегән яклар арасында гадел бүлү;

6) дәүләти-хосусый партнерлык турындагы килешүне төзү иреге.

4 статья. **Дәүләти-хосусый партнерлык өлкәсендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты вәкаләтләре**

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты:

1) Татарстан Республикасы исеменнән гавами партнер вәкаләтләрен гамәлгә ашыру максатларында Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнарын билгели;

2) Федераль законның 17 статьясындагы 2 өлешендә, әлеге Законның 5 статьясында каралган вәкаләтләрне гамәлгә ашыручы Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органын (алга таба – вәкаләтле орган) билгели;

3) Татарстан Республикасы гавами партнер булып торган дәүләти-хосусый партнерлык турындагы килешүләр реестрын алып бару тәртибен билгели;

4) Татарстан Республикасы гавами партнер булып торган дәүләти-хосусый партнерлык турындагы килешүне эшләгәндә һәм гамәлгә ашырганда ведомствоара хезмәттәшлек регламентын раслый;

5) Татарстан Республикасы гавами партнер булып торса йә Татарстан Республикасы катнашында уртак конкурс уздыру планлаштырылса (Россия Федерациясе катнашында уртак конкурс уздыру планлаштырылган очраклардан тыш), дәүләти-хосусый партнерлык проектын гамәлгә ашыру турында карар кабул итә, шул исәптән дәүләти-хосусый партнерлыкта катнашу рәвешен билгели;

6) Федераль законда, Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнарында һәм башка норматив хокукый актларында каралган башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыра.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты дәүләти-хосусый партнерлык проектын Федераль законның 9 статьясындагы 2 – 5 өлешләре нигезендә анық нәтиҗәлелеген бәяләү һәм чагыштырма өстенлеген билгеләү өчен инвестиция эшчәнлеге өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыруга вәкаләтле федераль башкарма хакимият органына җибәрергә хокуклы.

5 статья. **Дәүләти-хосусый партнерлык өлкәсендә вәкаләтле орган вәкаләтләре**

Вәкаләтле орган:

1) Татарстан Республикасы гавами партнер булып торган дәүләти-хосусый партнерлык турындагы килешүне йә Татарстан Республикасы катнашында уртак конкурс уздыру планлаштырылган дәүләти-хосусый партнерлык турындагы килешүне гамәлгә ашырганда (Россия Федерациясе катнашында уртак конкурс уздыру планлаштырылган очраклардан тыш) Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары эшчәнлеген ведомствоара координацияләүне тәэмин итә;

2) әгәр дәүләти-хосусый партнерлык проектын эшләү инициаторы Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органы булса, әлеге проектны гамәлгә ашыру турындагы тәкъдимнәрне алдан карауны гавами партнер белән берлектә оештыра;

3) Татарстан Республикасы гавами партнер булып торган дәүләти-хосусый партнерлык проектының нәтиҗәлелеген бәяли һәм Федераль законның 9 статьясындагы 2 – 5 өлешләре нигезендә әлеге проектның чагыштырма өстенлеген билгели;

4) Татарстан Республикасы гавами партнер булып торган дәүләти-хосусый партнерлык килешүен төзү хокукына конкурслар уздыру өчен конкурс документациясен гавами партнер белән килештерүне гамәлгә ашыра;

5) дәүләти-хосусый партнерлык турындагы килешүләрнең гамәлгә ашырылуына мониторинг ясый;

6) дәүләти-хосусый партнерлык турындагы килешүне гамәлгә ашыру барышында гавами партнерларның һәм хосусый партнерларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклауда булышлык күрсәтә;

7) дәүләти-хосусый партнерлык турында төзелгән килешүләр реестрын алып баруны гамәлгә ашыра;

8) әгәр килешүдә Татарстан Республикасы гавами партнер буларак катнашса, дәүләти-хосусый партнерлык турында төзелгән килешүләр турындагы мәгълүматның ачыклыгын һәм һәркем файдаланырлык булуын тәэмин итә;

9) Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән федераль башкарма хакимият органына килешү йөкләмәләре буенча Татарстан Республикасы гавами партнер булып торган дәүләти-хосусый партнерлык турындагы килешүнең йә Татарстан Республикасы катнашында уртак конкурс уздыру нигезендә төзелгән килешүнең гамәлгә ашырылуына ясалган мониторинг нәтиҗәләрен тапшыра;

10) Федераль законда, башка федераль законнарда, Татарстан Республикасы законнарында һәм башка норматив хокукый актларында каралган бүтән вәкаләтләрне гамәлгә ашыра.

6 статья. **Дәүләти-хосусый партнерлык турындагы килешүне әзерләү, төзү, үтәү һәм туктату тәртибе**

Дәүләти-хосусый партнерлык проектын гамәлгә ашыру турында тәкъдимне әзерләү, аның вәкаләтле орган тарафыннан каралуы, дәүләти-хосусый партнерлык проектын гамәлгә ашыру турында карар кабул итү, дәүләти-хосусый партнерлык турында килешү төзү, үтәү һәм туктату Федераль закон нигезендә башкарыла.

7 статья. **Татарстан Республикасының дәүләти-хосусый партнерлыкта катнашу рәвешләре**

1. Татарстан Республикасының дәүләти-хосусый партнерлыкта катнашуы Федераль закон белән билгеләнгән тәртиптә финанс, мөлкәт рәвешләрендә, мәгълүмат-консультация ярдәме рәвешендә һәм законнарга каршы килми торган башка рәвешләрдә түбәндәге юллар белән гамәлгә ашырыла:

1) дәүләти-хосусый партнерлык турындагы килешү объектының хосусый партнер тарафыннан төзелүен, аннан файдалануны һәм (яисә) аңа техник хезмәт күрсәтүне Россия Федерациясе законнары нигезендә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү хисабына финанслау;

2) хосусый партнерга дәүләти-хосусый партнерлык турындагы килешү объекты урнашкан йә төзелә торган һәм (яисә) дәүләти-хосусый партнерлык турындагы килешүдә каралган эшчәнлекнең хосусый партнер тарафыннан гамәлгә ашырылуы өчен кирәкле җир кишәрлекләрен җир законнарында каралган очракларда һәм тәртиптә торглар уздырмыйча гына арендага бирү;

3) хосусый партнерга Татарстан Республикасы милкендәге күчемсез һәм (яисә) күчемле мөлкәтне Татарстан Республикасы законнары нигезендә ышанычлы идарәгә, аңа хуҗа булуга һәм (яисә) аннан файдалануга тапшыру;

4) хосусый партнерга дәүләти-хосусый партнерлык проектын гамәлгә ашыру өчен кирәкле икътисадый, хокукый, производство-технологиягә кагылышлы мәгълүматны урнаштыру өчен региональ мәгълүмат системаларын һәм мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләрен бирү;

5) хосусый партнерга дәүләти-хосусый партнерлык турындагы килешү буенча җитештерелә торган товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне тәкъдим итү өчен

күргәзмәләр, форумнар һәм башка (шул исәптән халыкара) чаралар үткәрүдә һәм катнашуда булышлык күрсәтү;

6) башка ысуллар белән.

2. Татарстан Республикасының дәүләти-хосусый партнерлыкта катнашуы бер яки берничә рәвештә гамәлгә ашырылырга мөмкин.

8 статья. **Дәүләти-хосусый партнерлык турындагы килешүнең үтәлешен тикшереп тору**

1. Гавами партнер хосусый партнерның дәүләти-хосусый партнерлык турындагы килешү шартларын үтәвен, шул исәптән килешү объектын проектлау, төзү срокларына сыешуын, килешү объектын төзүне финанславын, килешү объектының техник-икътисадый күрсәткечләренең килешүдә каралган техник-икътисадый күрсәткечләргә туры килүен, килешүдә каралган эшчәнлекнең гамәлгә ашырылуын, килешү объектының килешүдә каралган максатларда файдаланылуын, шулай ук вәкаләтле органның уңай бәяләмә бирүе өчен нигез булган проект нәтиҗәлелеге критерийлары күрсәткечләренә һәм чагыштырма өстенлеге күрсәткечләренә ирешүен тикшереп тора.

2. Гавами партнер дәүләти-хосусый партнерлык турындагы килешү үтәлешен, шул исәптән хосусый партнерның дәүләти-хосусый партнерлык турындагы килешү шартларының үтәвен, федераль законнар белән билгеләнгән тәртиптә тикшереп тора.

3. Хосусый партнер тарафыннан дәүләти-хосусый партнерлык турындагы килешү шартларының үтәлешен тикшерүдән алынган нәтиҗәләр тикшерү нәтиҗәләре турындагы акт белән рәсмиләштерелә.

4. Тикшерү нәтиҗәләре турындагы акт мондый акт төзелгән көннән алып биш көн эчендә “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә гавами партнерның рәсми сайтына урнаштырылырга тиеш. Күрсәтелгән актны карау мөмкинлеге дәүләти-хосусый партнерлык турындагы килешүнең гамәлдә булу срогы дәвамында һәм килешү вакыты чыккан көннән соң өч ел дәвамында тәэмин ителә.

9 статья. **Коллегиаль киңәшмә орган**

Дәүләти-хосусый партнерлыкны үстерүнең төп юнәлешләрен билгеләү һәм Татарстан Республикасында дәүләти-хосусый партнерлык механизмнарын камилләштерүгә юнәлтелгән башка мәсьәләләрне хәл итүне Татарстан Республикасы Президенты вәкаләтләр биргән Татарстан Республикасында инвестиция климатын яхшырту буенча коллегиаль киңәшмә орган гамәлгә ашыра.”.

**2 статья**

Татарстан Республикасының “Татарстан Республикасында дәүләти-хосусый партнерлык турында” 2011 елның 1 августындагы 50-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә әлеге Закон үз көченә кергән көнгә кадәр төзелгән

килешүләргә карата шул Татарстан Республикасы Законы нигезләмәләре (әлеге Закон үз көченә кергәнче гамәлдә булган редакциядә) кулланыла. Мондый килешүләр нинди шартларда төзелгән булса, шул шартларда аларның гамәлдә булу срогы тәмамланганчы гамәлдә була.

**3 статья**

1. Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты үз норматив хокукый актларын әлеге Законга туры китерергә, шулай ук әлеге Законны гамәлгә ашыруны тәэмин итә торган Татарстан Республикасы норматив хокукый актларын эшләүне һәм кабул итүне тәэмин итәргә тиеш.

Татарстан Республикасы
Президенты — Р.Н. Миңнеханов

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ • АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан,Кремль
2016 елның 23 апреле
№ 25-ТРЗ